РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОЧЕЧКАБСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА ЧӘЧКАП
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

« 11 » сентябрь 2020 ел

№ 10

Җир кишәрлегенә почта адресын бирү (үзгәртү, төгәлләштерү)
буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ
регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару Кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 февралендәге 880 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап авыл җирлеге Башкарма комитетының «Җир кишәрлегенә почта адресын бирү (үзгәртү, төгәлләштерү) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 20 маендагы 21 номерлы карары белән расланган (2019 елның 22 ноябрендәге 39 номерлы карар редакциясендә) җир кишәрлегенә почта адресын бирү (үзгәртү, төгәлләштерү) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 2.9 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Адресны адреслау объектына бирү яки аның адресын гамәлдән чыгару түбәндәге очракларда кире кагылырга мөмкин:<br>а) адрес объектына адресны бирү турында гариза белән Кагыйдәләрнең 27 һәм 29 пунктларында күрсәтелмәгән зат мөрәҗәгать итте;<br>б) ведомствоара запроска җавап объектка адресны бирү яки аның адресын юкка чыгару өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүматның булмавын | |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәтә, һәм тиешле документ мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүче вәкиле) тарафыннан үз инициативасы буенча тапшырылмаган;<br>в) адресны бирү яисә аның адресын юкка чыгару өчен гариза бирүчегә (мөрәҗәгать итүче вәкиленә) йөкләнгән документлар, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртипне бозып бирелгән;<br>г) объектка адресны бирү яки аның адресын юкка чыгару өчен, Кагыйдәләрнең 5, 8-11 һәм 14-18 пунктларында күрсәтелгән очраклар һәм шартлар юк. | |

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

ТР Буа муниципаль районы
Яңа Чәчкап авыл
җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Д. Абдрахманова